ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июнь 2021ел № 4016

Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибен раслау турында

Яр Чаллы шәһәре, Габдулла Тукай исемендәге яр буе һәм В. Гостев урамы кисешкән район адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:52:0000004009 булган җир участогында спорт-сәламәтләндерү комплексы төзү һәм киләчәктә аны эксплуатацияләү буенча муниципаль-шәхси партнерлык турында 2018 елның 26 апрелендәге килешүне тормышка ашыру максатында һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетының Үзәк районы хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетының Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетының Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 15 июнендәге
4016 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибе

1. Әлеге тәртип Яр Чаллы шәһәре, Габдулла Тукай исемендәге яр буе һәм В. Гостев урамы кисешкән район адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:52:0000004009 булган җир участогында спорт-сәламәтләндерү комплексы төзү һәм киләчәктә аны эксплуатацияләү буенча 2018 елның 26 апрелендәге муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүне (алга таба – Килешү) тормышка ашыру кысаларында «Клеверспорт» спорт-сәламәтләндерү үзәге (алга таба – сәламәтләндерү үзәге) тарафыннан түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен билгели.

2. Сәламәтләндерү үзәгенә түләүсез йөрү хокукына ия гражданнар категорияләренең исемлеге:

1) аз керемле гаиләдәге балалар;

2) сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар;

3) шәһәр халкы.

3. Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән затларга сәламәтләндерү үзәге тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрләре:

1) сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар өчен бассейнда тренер белән сәламәтләндерү дәресе;

2) сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар өчен тренер белән дәвалау физкультурасы дәресе;

3) 12 яшьтән 14 яшькә кадәрге балалар өчен бассейнда тренер белән сәламәтләндерү дәресе;

4) 12 яшьтән 14 яшькә кадәрге балалар өчен тренер белән бергә-бер көрәш стилендә сәламәтләндерү гимнастикасы буенча төркемле дәрес;

5) 9 яшьтән 11 яшькә кадәрге балалар өчен тренер белән фитнес буенча төркемле сәламәтләндерү дәресе;

6) ачык һавада тренер белән йога буенча төркемле дәрес;

7) ачык һавада тренер белән аква-зона төркемле сәламәтләндерү дәресе.

4. Сәламәтләндерү үзәге тарафыннан түләүсез нигездә физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү (алга таба – абонементлар бирү), бер тапкыр үткәрү мөмкинлегеннән, эш режимыннан, дәресләрнең расланган расписаниеләреннән, сеансларның тыгызлыгыннан һәм башка факторлардан чыгып, сәламәтләндерү үзәгенең техник мөмкинлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Ташламалы сеансның (дәреснең) көне һәм вакыты, шулай ук аларның дәвамлылыгы сәламәтләндерү үзәге директорының боерыгы белән раслана.

Абонемент, хезмәттән түләүсез файдалану хокукыннан файдаланучы затларны алга таба алыштырып (ротация), 3 ай срокка бирелә. Хезмәттән елга бер тапкыр файдаланырга мөмкин. Файдалана торган хезмәтләр реестры район хакимияте тарафыннан алып барыла.

## II. Гражданнарның ташламалы категориясенә хезмәтләр күрсәтү (абонементлар бирү) өчен гаризалар бирү һәм аларны карап тикшерү тәртибе

5. Абонемент бирү өчен, әлеге тәртипнең 2 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән затлар (яки аның законлы вәкиле) яшәү урыны буенча район хакимиятенә әлеге тәртипнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча гариза һәм әлеге тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә гражданнарның һәр категориясе өчен билгеләнгән документлар тапшыра.

6. Документларны тапшыру вакыты:

- гыйнвар-март айларына: агымдагы елның 15 декабреннән 25 декабренә кадәр;
- апрель-июнь айларына: агымдагы елның 15 мартыннан 25 мартына кадәр;
- июль-сентябрь айларына: агымдагы елның 15 июненнән 25 июненә кадәр;
- октябрь-декабрь айларына: агымдагы елның 15 сентябреннән 25 сентябренә кадәр.

7. Район хакимиятенең җаваплы хезмәткәре:

1) документларны кабул итү тәртибен аңлата, мөрәҗәгать иткән затларга абонемент бирү тәртибе турында хәбәр итә;

2) гариза бирүчеләрдән әлеге тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны кабул итә;

3) тапшырылган документларны, алардагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында һәм тәртиптә мондый документларның эчтәлегенә һәм рәсмиләштерүгә карата куелган таләпләргә туры килүен тикшерүне гамәлгә ашыра;

4) әлеге тәртипнең 11 пункты нигезендә абонемент бирүдән баш тарту өчен нигезләр булуны яки булмауны билгели.

Абонемент бирүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, гариза бирүчегә абонемент бирүгә комачаулый торган, ачыкланган нигезләр турында телдән хәбәр итә һәм тапшырылган гаризаны һәм документларны аңа кире кайтара.

Абонемент бирүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, гаризаны һәм документларны теркәгәннән соң, гариза бирүчене сәламәтләндерү үзәгенә җибәрү өчен Бердәм реестрга кертә;

5) әлеге тәртипнең 6 пункты нигезендә документлар тапшыру вакыты тәмамланганнан соң, Бердәм реестр формалаштыра һәм сәламәтләндерү үзәгенә җибәрә.

8. Әлеге тәртипнең 2 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән затларга хезмәтләр күрсәтү тәртибе сәламәтләндерү үзәгенең эчке регламенты белән регламентлана.

## III. Хезмәтләр күрсәтү (абонементлар бирү) тәртибе

9. Абонементлар Килешү нигезендә, сәламәтләндерү үзәге тарафыннан билгеләнгән кварталлык лимит чикләрендә, гариза бирүченең район хакимиятенә мөрәҗәгать итү датасыннан чыгып чират тәртибендә бирелә.

10. Абонементлар гариза бирүчегә, имза куйдырып, өч айга бирелә.

11. Абонемент бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар әлеге тәртип таләпләренә туры килмәү;

2) гариза бирүче тарафыннан әлеге тәртипнең 5 пунктында каралган документларның тулы булмаган исемлеге тапшырылу;

3) гариза бирүченең, аңа сәламәтләндерү үзәгендә абонемент буенча билгеләнгән хезмәтләрдән файдаланырга мөмкинлек бирми торган билгеләр булу турында медицина бәяләмәсе алу;

4) гариза бирүченең бирелгән абонементтан баш тарту турында язмача гаризасы;

5) нигезле сәбәпләрсез 1 айдан артык сәламәтләндерү үзәгендә абонемент буенча бирелгән хезмәттән файдаланмау;

6) гариза бирүче тарафыннан сәламәтләндерү үзәгенең эчке кагыйдәләрен бозу, санитар нормаларны һәм кагыйдәләрне бозу, хулиганлык гамәлләре, вандаллык кылу, сәламәтләндерү үзәге мөлкәтенә аңлы рәвештә зыян китерү;

7) сәламәтләндерү үзәгенә алкоголь, наркотик яки башка токсик исереклек хәлендә килү;

8) башка затларга сәламәтләндерү үзәге ресурсларыннан файдаланырга комачаулый торган һәм/яки башка затларның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерә торган яки башка затларның мөлкәтенә зыян китерә торган гамәлләр кылу (гамәл кылмау);

9) сәламәтләндерү үзәгенең гариза бирүчеләргә әлеге тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән абонементлар бирү буенча кварталлык лимиты бетү;

10) әлеге тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән чорлар чикләреннән тыш һәм билгеләнгән срокларны бозып хезмәт күрсәтүне (абонемент бирүне) сорап мөрәҗәгать итү.

12. Гариза бирүче, ташламалы абонемент булмаган шартларда, аны алу өчен сәламәтләндерү үзәгенә мөрәҗәгать иткән очракта, район хакимиятенең җаваплы хезмәткәре аны киләсе кварталда хезмәттән файдалануга (абонемент алуга) гариза бирүчеләр исемлегенә кертә.

## IV. Бирелгән абонементлар исәбен алып бару

13. Сәламәтләндерү үзәге һәм район хакимияте тарафыннан бирелгән абонементлар исәбе алып барыла.

14. Бирелгән абонементлар исәпкә алу журналында теркәлә. Журнал хронологик тәртиптә алып барыла.

15. Сәламәтләндерү үзәге, квартал саен, хисап кварталының соңгы аеннан соң килгән айның 20 числосыннан соңга калмыйча, хисап ведомостен формалаштыра һәм район хакимиятенә җибәрә.

16. 11 пунктның 4-8 пунктчалары нигезендә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, сәламәтләндерү үзәге 3 көн эчендә район хакимиятенә хәбәр итә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибенә
1 нче кушымта

«Клеверспорт» спорт-сәламәтләндерү комплексы директорына

кемнән ___________________________

___________________________________
(Ф.И.А.и. тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яшәүче:

___________________________________

___________________________________

Паспорт ___________________________
Бирелгән __________________________

___________________________________

Телефон___________________________

Гариза

Минем балигъ булмаган балама

_______________________________________________________________________
(баланың Ф.И.А. и. тулысынча)

түләүсез хезмәт(ләр) күрсәтүне сорыйм.

_______________________________________________________________________

| № т/б | Хезмәтләрнең төре | Хезмәт күрсәтү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | көн | сәгать | |
| 1 | Бассейн | | | |
| 2 | Фитнес | | | |
| 3 | Бергә-бер көрәш | | | |

Балигъ булмаган балаларымның сәламәтлегенә бәйле барлык куркынычларны (хроник авырулар, яшерен авырулар, чиктән тыш күп эш һ.б.) үз өстемә алам. «Клеверспорт» ҖЧҖгә йөрү кагыйдәләре, түләүсез нигездә хезмәтләр күрсәтү тәртибе белән таныштым:

_______________/_____________________________________________/_______________
имза Ф.И.А.и. тулысынча дата

Гаризага түбәндәге документларны терким:
1___________________________________________________________________
2___________________________________________________________________
3___________________________________________________________________
4___________________________________________________________________

«Клеверспорт» спорт-
сәламәтләндерү комплексы
директорына

кемнән ______________________________
____________________________________
(Ф.И.А.и. тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яшәүче:
____________________________________
____________________________________
Паспорт ___________________________
Бирелгән __________________________
____________________________________
Телефон___________________________

Гариза

Миңа түләүсез нигездә хезмәт(ләр) күрсәтүне сорыйм

| № т/б | Хезмәтләрнең төре | Хезмәт күрсәтү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | көн | сәгать | |
| 1 | Бассейн | | | |
| 2 | Студиядә дәвалау физкультурасы | | | |

Үз сәламәтлегемә белән бәйле барлык куркынычларны (хроник авырулар, яшерен авырулар, чиктән тыш күп эш һ.б.) үз өстемә алам. «Клеверспорт» ҖЧҖгә йөрү кагыйдәләре, түләүсез нигездә хезмәтләр күрсәтү тәртибе белән таныштым:

_______________/____________________________________________/__________________
имза Ф.И.А.и. тулысынча дата

Гаризага түбәндәге документларны терким:
1______________________________________________________________
2______________________________________________________________
3______________________________________________________________
4______________________________________________________________

Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибенә
2 нче кушымта

Абонемент алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге

Сәламәтләндерү үзәгенә түләүсез йөрү хокукына ия гражданнар гариза белән бергә түбәндәге документларны район хакимиятенә тапшыралар:

1) шәхесне раслаучы документ күчермәсе;

2) туу турында таныклык күчермәсе;

3) Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 24 ноябрендәге 1031н номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча, Медицина-социаль экспертиза Федераль дәүләт учреждениесе тарафыннан бирелә торган инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмә күчермәсе;

4) яшәү минимумыннан түбән керемле гаиләләр өчен – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендәге социаль яклау идарәсе тарафыннан бирелгән, ташламага ия бала гаиләсен аз керемле дип тану турында таныклаучы белешмә;

5) сәламәтләндерү үзәгенә йөрү өчен рөхсәт бирелү һәм йөзү белән шөгыльләнергә ярамый торган торган медицина күрсәтмәләре булмау турында участок терапевтыннан медицина белешмәсе.